Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында" 2005 елның 22 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (II өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә

органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 7 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында "Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга;

3) 9 статьяда "Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10 статья. **Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

1. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына әлеге Закон белән тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тикшереп тора.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәге рәвешләрдә башкарыла:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән матди һәм финанс чараларының муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан тотылуы өлешендә комплекслы тикшерүләр уздыру, хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү;

2) тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны күзәтеп тору өчен вәкаләтле вазыйфаи затларны билгеләп кую;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча кабул ителгән муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза һәм анализ ясау;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә анализ ясау һәм күрсәтелгән органнарның эшчәнлеген камилләштерү яисә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертү.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында каралган чаралар кирәк булганда, шул исәптән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге Закон таләпләрен йә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бюджет законнары таләпләрен бозуларны таныклый торган фактлар ачыкланганда, үткәрелә.

4. Әлеге статьяның 2 өлешендәге 3 пунктында каралган чаралар ел саен агымдагы финанс елының 1 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында каралган чаралар ел саен агымдагы финанс елының 31 декабренә кадәр гамәлгә ашырыла.";

5) 12 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга;

6) 3 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"**____________________ муниципаль районы буенча җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап**".

**2 статья**

"Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 142-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 7 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларында "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә

ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.";

4) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча,

шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тәэмин итү өлешендә, түбәндәге юллар белән:

кирәкле мәгълүматны, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларын, муниципаль хокукый актларны соратып алу;

тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларына һәм муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза үткәрү һәм анализ ясау.";

5) 11 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең халыкны социаль яклау өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең халыкны социаль яклау өлкәсендәге махсус вәкаләтле органына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

"Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма

хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

"4. Җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт вәкаләтләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылуын тикшереп торуда кирәкле ярдәм күрсәтергә тиеш.";

3) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.";

4) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып

алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.";

5) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10 статья. **Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату Татарстан Республикасы законы нигезендә түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

1) җирле үзидарә органнары тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

2) җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары әлеге Законны бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрне үтәмәгәндә;

3) федераль законнарны яисә Татарстан Республикасы законнарын җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мөмкин булмаслык итеп үзгәрткәндә.

2. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы туктатылганда, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылып, кулланылмый калган финанс һәм матди чаралар кире кайтарыла.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы әлеге бозуларны ачыклаган көннән алып 10 көн эчендә аларны бетерү турында җирле үзидарә органнарына күрсәтмә юллый.

4. Ачыкланган бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органнарына кергән көннән алып 10 көн узганчы каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең

яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органына кичекмәстән язмача хәбәр ителәэ.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турындагы тәкъдимне һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын кертә.".

**4 статья**

"Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

"4. Җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт вәкаләтләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылуын тикшереп торуда кирәкле ярдәм күрсәтергә тиеш.";

3) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органына

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 нче числосына кадәр тапшырыла.";

4) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.";

5) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын туктату Татарстан Республикасы законы нигезендә түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

1) җирле үзидарә органнары тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

2) җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары әлеге Законны бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәне үтәмәгәндә;

3) федераль законнарны яисә Татарстан Республикасы законнарын җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мөмкин булмаслык итеп үзгәрткәндә.

2. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы туктатылганда, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылып, кулланылмый калган финанс һәм матди чаралар кире кайтарыла.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча закон таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы әлеге бозуларны ачыклаган көннән алып 10 көн эчендә аларны бетерү турында җирле үзидарә органнарына күрсәтмә юллый.

4. Ачыкланган бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органнарына кергән көннән алып 10 көн узганчы каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органына кичекмәстән язмача хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турындагы тәкъдимне һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын кертә.".

**5 статья**

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән граждан хәле актларын теркәү таныклыклары бланкларыннан һәм махсус компьютер программалары

чараларыннан тыш, Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 4 статьяда:

а) 1 өлештә:

бишенче абзацта тиешле килештәге "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең компетенциясенә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеген оештыру керә торган вәкаләтле органы" сүзләрен тиешле килештәге "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы абзац өстәргә:

"Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торуда кирәкле ярдәм күрсәтү;";

алтынчы абзацны җиденче абзац дип санарга;

б) 2 өлештә:

өченче һәм дүртенче абзацларда "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең компетенциясенә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеген оештыру керә торган вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

"Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торуда кирәкле ярдәм күрсәтү.";

в) 3 өлештәге өченче абзацта "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең компетенциясенә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеген оештыру керә торган вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяның 1 өлешендәге өченче абзацында "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең компетенциясенә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеген оештыру керә торган вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

4) 6 статьяның 1 өлешендә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең компетенциясенә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеген оештыру керә торган вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

5) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

1. Шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән рәвештә түбәндәге хисапларны тапшыралар:

1) ай саен хисап аеннан соң килә торган айның бишенче числосына кадәр:

муниципаль берәмлек башкарма комитетының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җыелма хисабы;

муниципаль берәмлек башкарма комитетының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында хисабы;

муниципаль берәмлек башкарма комитетының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алган өчен һәм юридик әһәмиятле башка гамәлләр өчен гражданнар тарафыннан дәүләт пошлинасын түләү турында хисабы;

2) муниципаль берәмлек башкарма комитетының герблы таныклык бланклары йөреше турында хисабы – квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның бишенче числосына кадәр;

3) ел саен хисап елыннан соң килә торган елның 5 гыйнварына кадәр:

муниципаль берәмлек башкарма комитетының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында хисабы;

муниципаль берәмлек башкарма комитетының герблы таныклык бланклары йөреше турында хисабы.

2. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә түбәндәге хисапларны тапшыралар:

1) ай саен хисап аеннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр:

муниципаль берәмлек башкарма комитетының граждан хәле актларын дәүләт

теркәвенә алуга бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җыелма хисабы;

муниципаль берәмлек башкарма комитетының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында хисабы;

муниципаль берәмлек башкарма комитетының тууны дәүләт теркәвенә алу турында хисабы;

муниципаль берәмлек башкарма комитетының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алган өчен һәм юридик әһәмиятле башка гамәлләр өчен гражданнар тарафыннан дәүләт пошлинасын түләү турында хисабы;

2) муниципаль берәмлек башкарма комитетының герблы таныклык бланклары йөреше турында хисабы – квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр;

3) муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының граждан хәле актларын теркәү турындагы документларны якын һәм ерак чит илләрдән соратып алу хакында хисабы – һәр ярты ел саен хисап яртыеллыгыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр;

4) ел саен хисап елыннан соң килә торган елның 10 гыйнварына кадәр:

муниципаль берәмлек башкарма комитетының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында хисабы;

муниципаль район (шәһәр округы) буенча өйләнешүне яшьләре буенча дәүләт теркәвенә алу һәм өйләнешкән затларның никахтагы хәле турында хисап;

муниципаль район (шәһәр округы) буенча кияү һәм кәләшнең милләте буенча никахлар саны турында хисап;

муниципаль район (шәһәр округы) буенча аерылышучы затларның аерылышуын яшьләре буенча дәүләт теркәвенә алу һәм аерылышкан гаиләләрнең никахта булу дәвамлылыгы турында хисап;

муниципаль район (шәһәр округы) буенча элеккеге ир белән хатынның милли төсмерләре буенча аерылышкан гаиләләр саны турында хисап;

муниципаль берәмлек башкарма комитетының үлем очракларын дәүләт теркәвенә алу турында хисабы.";

6) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру, граждан хәле актлары турындагы законнар таләпләрен, шулай ук граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алганда гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү өлешендә, түбәндәге

юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

төгәл хисап бирү бланкларын – граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу таныклыкларын тиешенчә тотуны һәм саклауны тәэмин итү чараларын үткәрү, актлар китабын тиешенчә саклауны тәэмин итү;

граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга бәйле кирәкле мәгълүматны һәм документларны соратып алу;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән актларга хокукый экспертиза үткәрү һәм анализ ясау;

җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алудан баш тартуларын шикаять белдерү тәртибендә карау;

җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда хокук бозуларны бетерү турында язма күрсәтмәләр җибәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.";

7) 10 статьяның 3 һәм 4 өлешләрендә тиешле килештәге "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең компетенциясенә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеген оештыру керә торган вәкаләтле органы" сүзләрен тиешле килештәге "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлегенә идарә итү өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга.

**6 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш); 2010, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.";

3) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт**

**вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук закон бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук закон бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.";

4) 10 статьяның 3 һәм 4 өлешләрендә "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле башкарма органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга.

**7 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 6 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларында "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.";

4) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тәэмин итү өлешендә, түбәндәге юллар белән:

кирәкле мәгълүматны, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларын, муниципаль хокукый актларны соратып алу;

тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларына һәм муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза үткәрү һәм анализ ясау.";

5) 10 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга.

**8 статья**

"Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 17 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә рәвештә үз матди чараларыннан файдаланырга хокуклы.";

2) 8 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларында "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә

ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.";

4) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, комплекслы күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып

алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.";

5) 11 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә махсус вәкаләтле органына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга.

**9 статья**

"Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 7 апрелендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирелә:

республика яшьләр конкурсларының, күргәзмәләренең, фестивальләренең, яшь коллективлар смотрларының район (шәһәр) этапларын оештыру һәм уздыру;

яшьләр өчен төрле профильле махсуслаштырылган лагерьларның һәм башка үзәкләрнең эшен оештыру;

яшьләр хәрби-патриотик клубларының һәм эзләнү берләшмәләренең эшен оештыру өчен шартлар тудыру;

яшьләрнең яшәү урыннарында укыту-тренировка чараларын уздыруны гамәлгә ашыручы тренерларга ярдәм итү.";

2) 5 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма

хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

3) 6 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 6 пунктларында "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

4) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.";

5) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тәэмин итү өлешендә, түбәндәге юллар белән:

кирәкле мәгълүматны, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларын, муниципаль хокукый актларны соратып алу;

тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларына һәм муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза үткәрү һәм анализ ясау.";

6) 10 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча махсус вәкаләтле органына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга.

**10 статья**

"Чаллы шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 28 апрелендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4) түбәндәге

үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә рәвештә үз матди чараларыннан файдаланырга хокуклы.";

2) 7 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларында "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Статья 8. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

1. Халыкка тимер юл транспорты хезмәтләрен күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 27 нче числосына кадәр тапшырыла.

2. Халыкка эчке су транспорты хезмәтләрен күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә ай саен хисап аеннан соң килә торган айның 5 нче числосына кадәр тапшырыла.";

4) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тәэмин итү өлешендә, түбәндәге юллар белән:

кирәкле мәгълүматны, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен

җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларын, муниципаль хокукый актларны соратып алу;

тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларына һәм муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза үткәрү һәм анализ ясау.";

5) 10 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендәге махсус вәкаләтле органына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга.

**11 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына аерым категориядәге гражданнарга акчалата түләүләрне һәм өстәмә түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 7 декабрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органының һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгатьләре нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 6 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларында "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

1. Фельдшерлык-акушерлык пунктларының медицина персоналына, ашыгыч медицина ярдәме табибларына, фельдшерларына һәм шәфкать туташларына акчалата түләүләрне башкару буенча җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә ай саен хисап аеннан соң килә торган айның 10 нчы числосыннан да соңга калмыйча тапшырыла.

2. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчесе функцияләрен башкарган өчен түләүләрне башкару буенча җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә ай саен хисап аеннан соң килә торган айның 10 нчы числосыннан да соңга калмыйча тапшырыла.";

4) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – фельдшерлык-акушерлык пунктларының медицина персоналына, ашыгыч медицина ярдәме табибларына, фельдшерларына һәм шәфкать туташларына акчалата түләүләрне башкару буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчесе функцияләрен башкарган өчен түләүләрне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнарына

тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

4) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тәэмин итү өлешендә, түбәндәге юллар белән:

кирәкле мәгълүматны, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларын, муниципаль хокукый актларны соратып алу;

тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларына һәм

муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза үткәрү һәм анализ ясау.";

5) 10 статьяда:

а) 3 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле органына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга һәм "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә махсус вәкаләтле органына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле органы яисә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органы яисә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга.

**12 статья**

"Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына

бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 6 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларында "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә хисап кварталыннан соң килә торган айның җиденче числосыннан да соңга калмыйча тапшырыла.";

4) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, шулай ук муниципаль районнар бюджетларына җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларының максатчан кулланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә күчмә комплекслы тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

2) әлеге Закон белән каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.";

5) 10 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт финанслары өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "махсус" сүзен төшереп калдырырга.

**13 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары

тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 5 статьядагы 2 өлештә:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендә вәкаләтле органына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисапларны тапшыру;";

б) 6 пунктта "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә ярты ел саен хисап яртыеллыгыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.";

4) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып

алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдаланугa тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тәэмин итү өлешендә, түбәндәге юллар белән:

кирәкле мәгълүматны, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларын, муниципаль хокукый актларны соратып алу;

тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларына һәм муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза үткәрү һәм анализ ясау.";

5) 9 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендәге махсус вәкаләтле органына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең архив эше өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга.

**14 статья**

"Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары

җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез милекнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2010, 22 май) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең милек мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 6 статьяда:

а) 1 өлештәге 1 пунктта "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырырга вәкаләтле органыннан" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә вәкаләтле органыннан" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештәге 4 һәм 5 пунктларында "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.";

4) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә

ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә комплекслы тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.";

5) 10 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге, финанс һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә махсус вәкаләтле органнары" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә, финанс сәясәте өлкәсендә һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органнары" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге, финанс һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә махсус вәкаләтле органнарына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендә, финанс сәясәте өлкәсендә һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органнарына" сүзләренә алмаштырырга.

**15 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органының һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгатьләре нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

2) 5 статьяның 2 өлешендә:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органына һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисапларны тапшыру;";

б) 5 пунктта "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан

Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.

2. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр тапшырыла.";

4) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – суд тарафыннан хезмәткә сәләтсез яисә хезмәткә сәләте чикләнгән дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

4) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тәэмин итү өлешендә, түбәндәге юллар белән:

кирәкле мәгълүматны, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларын, муниципаль хокукый актларны соратып алу;

тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар проектларына һәм муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза үткәрү һәм анализ ясау.";

5) 9 статьяда:

а) 3 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 өлештә "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендәге махсус вәкаләтле органы һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендәге махсус вәкаләтле

органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга.

**16 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1.Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, Тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырыла.

Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә рәвештә үз матди чараларыннан файдаланырга хокуклы.";

2) 7 статьяның 2 өлешендәге 4 һәм 5 пунктларында "махсус" сүзен төшереп калдырырга;

3) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Статья 8. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән

рәвештә ай саен хисап аеннан соң килә торган айның сигезенче числосыннан да соңга калмыйча тапшырыла.";

4) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Җирле үзидарә органнарының үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук, кирәк булганда, планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны җирле үзидарә органнарына бушлай файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм тиешенчә файдаланылуы өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тарифларны дәүләт җайга салуы өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан – җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районда (шәһәр округында) бер бару исәбеннән җәмәгать транспорты хезмәтләрен түләүнең төбәк стандартларын куллануның дөреслеген тикшерү өлешендә, түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, кирәк булганда, күчмә комплекслы тикшерүләр үткәрү, шул исәптән элек соратып алынган документларны, хисапларны, мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозуның ачыкланган фактларына бәйле рәвештә дә;

хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча тиешле чаралар күрү.";

5) 10 статьяда:

а) 3 һәм 5 өлешләрдә "транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең махсус вәкаләтле органы" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органы" сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә "транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең махсус вәкаләтле органына" сүзләрен "Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органына" сүзләренә алмаштырырга.

**17 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

(Мөһер: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН — ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ)

Казан, Кремль
2010 елның 30 июле
№ 62- ТРЗ